| ГЛАВА АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**20 март 2024 ел** **№1**

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнары халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. “2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнары халык җыенын Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасында, Әлмәт авылы Ленин урамы 56 А йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Әлмәт авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (сабантуй мәйданына скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү );
4. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Әлмәт авылында зират коймасын буярга буяулар сатып алу);?

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Әлмәт авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

«Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Д.Ә.Газизов